Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге Советы

Питрәч авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

19 май, 2026 ел № 7

Питрәч ав.

Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2017 елның 18 августындагы 65 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә (2017 елның 15 декабрендәге 79 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 92, 2019 елның 8 октябрендәге 137 номерлы, 2022 елның 16 декабрендәге 60 номерлы, 2023 елның 31 мартындагы 69 номерлы үзгәрешләре белән) нигезендә карар бирәм:

1.Түбәндәге проект буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә:

- «Автотранспортны саклау» җир участогы шәхси торак төзелеше зонасында (Ж1) Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Питрәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре - Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Питрәч авыл җирлеге, Питрәч авылы, Гаврилова урамы адресы буенча урнашкан кадастр номеры 16:33:120112:1095, мәйданы 1483 кв.м булган җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы проекты.

2. Гавами тыңлаулар уздыруны оештыручы итеп Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетын билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлегенең гавами тыңлауларны оештыручы - башкарма комитетына җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә гавами тыңлаулар оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Гавами тыңлаулар үткәрү 2026 елның 5 июненнән дә соңга калмыйча төгәлләнергә тиеш дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Сөләйманов

СОВЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ